**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5457**
**24.09.2018**

2018-2019 елларның көзге-кышкы
чорына җылыту сезоны
башлану турында

2018-2019 елларның көзге-кышкы чоры якынлашу уңаеннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йорт бүлмәләре һәм торак йортлар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында» 2011 елның 6 маендагы 354 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Автоматлаштырылган индивидуаль җылылык пунктлары (алга таба – АИҖП) белән җиһазландырылган шәһәр торак фондын һәм шәһәрнең социаль билгеләнештәге объектларын (гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләрен, яшьләр оешмаларын), расланган температура графигына туры китереп, җылылык системасын автомат тоташтыру режимына күчерергә.

2. АИҖП белән җиһазландырылмаган объектларда җылыту сезоны башлануны билгеләргә:

1) шәһәрнең социаль билгеләнештәге объектлары (гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләре, яшьләр оешмалары) өчен – 2018 елның 26 сентябреннән;

2) сәнәгый һәм башка предприятиеләр һәм оешмалар өчен – җылылык белән тәэмин итүче оешмалар адресына мөрәҗәгать итеп, җылылык бирелгән вакыттан.

3. Җылылык челтәре һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, шулай ук күп фатирлы йортларның идарәче оешмалары, торак милекчеләре ширкәтләре һәм башка оешмалар җитәкчеләренә җылылык җибәрү һәм җылылык йөрткечнең сыйфаты буенча тиешле чаралар күрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин